**Гайнетдинова, Эльвира** Шәһәребез чиста булсын / Э. Гайнетдинова. - Текст : турыдан-туры // Шәһри Чаллы. – 2019. – №26 (12 апрель). – С.1.
***Төп сүзләр:*** *– Татарстан Республикасы – Экология – Яр Чаллы – «ЭКОяз-2019» акциясе*

# Шәһәребез чиста булсын



**2019 елның 1 апреленнән 1 июненә кадәр Чаллыда урам, ишегалларын төзекләндерү һәм чистарту буенча традицион санитар-экологик икеайлык игълан ителде. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, төп эшләр планы инде төзелгән, шуңа бәйле рәвештә, шәһәр штабы составы расланган һәм үткәрелəсе барлык чаралар да билгеләнгән. Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары Илья Зуев сүзләрен караганда, мондый чараларда һәрбер чаллылы катнашырга тиеш.**

"Шәһәрне чистарту һәм төзекләндерү буенча барлык эшләр дә быел юбилей елы билгесе астында үтәргә тиеш. Һәркем үзенә: "Бездә нәрсә тиешенчә эшләнмәгән? Шәхсән мин ничек ярдәм итә алам?", - дип сорарга һәм эшләргә тиеш", - ди урынбасар. Мәсәлән, 2018 елда шәһәр территорияләрен чистарту эшләрендә 120 меңнән артык кеше, 2200 оешма катнашкан. Барлыгы 7400 га мәйдан чүптән арындырылган. Шулай ук төзекләндерү һәм агачлар утырту буенча 30га якын өмә үткәрелгән.

Гадәттәгечә, шәһәрне төзекләндерү һәм җыештыру эшләрендә ТКХ предприятиеләре, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре, сәнәгать предприятиеләре, КАМАЗ бүлекчәләре катнаша. Кызганычка каршы, тирә-якны җыештыруда һәм төзекләндерүдә гараж җәмгыятьләре, туклану, сәүдә предприятиеләре шактый түбән активлык күрсәтә, «һәр җитәкчегә, район башлыкларына, уйланырга, башкачарак фикер йөртергә тәкъдим итәм. "Бу безгә карамый, бу сезнең оешма территориясе" дип түгел, ә бу безнең шәһәр, безнеә яшәү мохите дип эшләргә кирәк. Парклар, скверлар, бульварларны, яр буйларын төзекләндерү буенча язгы чорга өстәмә эш планын төзүдә яхшы булыр иде. «КАМАЗ»ның юбилееен бәйрәм итүгә әзерлек буенча безнең уртак зур эшебезгә һәркем үз өлешен кертсә иде", - диде Игорь Сергеевич. Микрорайоннарда төзекләндерә һәм чистарту эшләрен төп оештыручылар -территориаль иҗтимагый үзидарә рәисләре. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, аларның актив эше нәтиҗәсендә ел саен шәһәр һәм республика күләмендәге төзекләндерү проектлары арасында узучы конкурсларда ия булган грант акчасына балалар өчен уен һәм спорт комплекслары барлыкка килә, ишегалларыбыз үзгәрә.

Шулай ук Игорь Сергеевич идарәче оешмаларга кар озак эри торган урыннарны игътибардан читтә калдырмаска өндәде. Шуның өстенә, подъездлар, балалар һәм хуҗалык мәйданчыкларының торышын тикшерү, игълан такталарын граффити һәм белдерүләрдән чистарту; юлларда һәм ишегалларында чокырлы җирләрне ремонтлау, чәчәк түтәлләре, эскәмияләр, чүп савытлары булдыру да мөһим эшләрнең берсе булып тора.

Чүп-чарны яндыру катгый тыелуын да истән чыгармаска кирәк. Моның өчен ТР административ хокук бозулар кодексының 3.6 маддәсе буенча вазыйфаи затлар өчен - 15 меңнән 30 мең сумга кадәр, юридик затлар өчен 200 меңнән 500 мең сумга кадәр штраф каралган. Санитар чистартуда катнашучы барлык предприятие һәм учреждениеләргә чүп-чар һәм үсемлек калдыкларын аерым җыю тәэмин итәргә тиеш.

Шулай ук шәхси йорт территорияләре дә игътибардан читтә калырга тиеш түгел, дип белдерде урынбасар. "Бирeдә яшәүчеләрне җәлеп итеп, шәхси сектор территориясендә дә тәртип урнаштыру буенча җитди эш көтелә. Шәһәр чигендә 16 бакчачылык җәмгыте урнашкан, аларның хуҗҗалары үз участокларында һәм якын-тирә территорияләрдә тәртип урнаштырырга тиеш. Узган ел республика программасы буенча бакчачылык ширкатьләрендә чүп җыю өчен контейнер мәйданчыклары төзекләндерелде. Хәзер бакчачылар җыелган чүп-чарны вакытында чыгарып бетерергә, санкцияләнмәгән чүплекләр барлыкка килүгә юл куймаска, мәйданчыклар һәм контейнерлар, чүп җыю бункерларын чистартырга тиеш.

Апрельнең соңгы шимбәсендә, ягъни 27сендә, шәһәр зиратларында традицион Хәтер көне чарасы үтәчәк. Ябык зиратлар территорияләрен чистартуга, агачлар һәм куаклар кисүгә, ауган агачларны, чүп-чар җыюга һәм чыгаруга аерым игътибар бирергә кирәк.

Бер әйберне истән чыгармаска кирәк: кешенең яхшы күңеллелеге аның җыештырылган ишегалдыннан һәм чиста шәһәреннән күренә.

**Эльвира ГАЙНЕТДИНОВА Солтан ИСХАКОВ фотосы**